**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**От13.04.2023** **№ 464**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль милек объектларына капитал салулар рәвешендә бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру һәм күрсәтелгән объектларга бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 79 статьясының 2 пункты нигезендә Башкарма комитет карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль милек объектларына капитал салулар рәвешендә бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру һәм күрсәтелгән объектларга бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү тәртибен расларга (1нче кушымта).

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен конрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
13.04.2023 елның 464
номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль милек объектларына капитал салулар рәвешендә бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру һәм күрсәтелгән объектларга бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 79 статьясы нигезендә Биектау муниципаль районының муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре бирү һәм күрсәтелгән объектларга бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү тәртибен билгели.

2. Бюджет инвестицияләре дигәндә, Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән муниципаль милек бәясен төзүгә яисә арттыруга юнәлдерелә торган бюджет акчалары аңлашыла.

3. Бюджет инвестицияләре капитал салуларны финанслау максатларында федераль һәм республика бюджетлары акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

4. Бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә төзелгән яисә сатып алынган капиталь төзелеш объектлары яисә күчемсез мөлкәт объектлары муниципаль учреждениеләргә, муниципаль унитар предприятиеләргә оператив идарә итү яисә хуҗалык алып бару хокукында билгеләнгән тәртиптә беркетелә, аннары муниципаль учреждениеләрдә оператив идарә хокукындагы йә муниципаль унитар предприятиеләрдә оператив идарә итү яисә хуҗалык алып бару хокукындагы, шулай ук хуҗалык алып бару хокукына нигезләнгән күрсәтелгән предприятиеләрнең устав фонды хакын арттырып йә муниципаль казна составына кертелә.

5. Биектау муниципаль районы бюджетын үтәгәндә муниципаль милек объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре бирү рөхсәт ителми.

6. Капиталь кертемнәргә бюджет инвестицияләре бирү муниципаль программалар яисә эшчәнлекнең программада каралмаган юнәлешләре кысаларында күрсәтелгән максатларга Биектау муниципаль районы башкарма комитетына (алга таба - район башкарма комитеты) каралган җыелма бюджет язмасы һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджеты турындагы Биектау муниципаль районы Советының карары белән расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

7. Бюджет инвестицияләренә бәйле чыгымнар объектлар төзү (реконструкцияләү) һәм (яисә) сатып алу максатларында төзелгән муниципаль контрактлар нигезендә Россия Федерациясенең бюджет законнарында һәм Биектау муниципаль районының норматив актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

8. Биектау муниципаль районындагы бюджет инвестицияләренең муниципаль заказчысы булып, Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә бюджет йөкләмәләрен кабул итәргә вәкаләтле һәм сатып алуны гамәлгә ашыручы Биектау муниципаль районы исеменнән эш итүче район башкарма комитеты тора.

9. Муниципаль заказчы килешү нигезендә түләүсез нигездә үзенең Биектау муниципаль районы муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда, күрсәтелгән орган исеменнән Биектау муниципаль районы исеменнән муниципаль контрактларны төзү һәм үтәү буенча (алга таба - вәкаләтләр тапшыру турында килешү) муниципаль заказчы вәкаләтләрен аларга карата әлеге орган учредитель функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләргә, яисә аларга карата күрсәтелгән орган гавами-хокукый берәмлек мөлкәте милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган муниципаль унитар предприятиеләргә тапшырырга хокуклы.

10. Муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру һәм (яисә) күчемсез милек объектларын муниципаль милеккә сатып алу турындагы карарны (алга таба - карар) районның башкарма комитеты түбәндәгеләрне исәпкә алып кабул итә:

1) Биектау муниципаль районын үстерүнең өстенлекләрен һәм максатларын;

2) Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразын;

3) Биектау муниципаль районы бюджет сәясәтенең төп юнәлешләрен;

4) капиталь кертемнәргә җибәрелә торган Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге анализын;

5) Биектау муниципаль районының комплекслы үсешенә капиталь төзелеш объекты һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектын сатып алу йогынтысын бәяләү;

6) Биектау муниципаль районы бюджетының финанс мөмкинлекләре.

11. Бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карар проекты түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) капиталь төзелеш объекты исемен йә күчемсез мөлкәт объекты исемен;

2) объектның хәзерге йә планлаштырыла торган урынын;

3) инвестицияләү юнәлешен (төзелеш (реконструкция, шул исәптән реставрация элементлары белән), техник яктан яңадан коралландыру, сатып алу));

4) бюджет акчаларының баш бүлүчесе һәм муниципаль заказчы исемен;

5) капиталь төзелеш объектын (күчемсез мөлкәт объектын) турыдан-туры тасвирлаучы параметрларын;

6) объектны эксплуатациягә кертү (сатып алу) срогы;

7) капиталь төзелеш объектының смета бәясен йә күчемсез мөлкәт объектын сатып алу бәясен (тиешле еллар бәяләрендә);

8) финанс белән тәэмин итү чыганаклары һәм проектны гамәлгә ашыру еллары буенча бюджет инвестицияләренең гомуми (чикле) күләме.

12. Бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карар проектын әзерләүнең инициаторы булып район башкарма комитетының тиешле

эшчәнлек өлкәсендә билгеләнгән тәртиптә вәкаләтләр бирелгән тармак органы (бүлекчәсе) тора.

13. Бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карар проекты район башкарма комитетының карар проекты рәвешендә рәсмиләштерелә.

14. Бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карар проекты белән берничә капиталь төзелеш объекты яисә күчемсез милек объектлары каралырга мөмкин.